2019 ел, ДЕКАБРЬ

киләчәкне яктырта

# Яшьлек







# Котлау!

Кадерле укытучылар, гимназия коллективы, укучылар һәм ата-аналар!

2019 нче ел ахырына якынлашып килә. Матур гадәт буенча, без аңа нәтиҗә ясыйбыз һәм киләчәккә планнарыбыз белән уртаклашабыз. Яңа ел - һәрчак якты өметләр бәйрәме.

Үтеп баручы елда без өстебезгә алынган барлык йөкләмәләрне үтәдек, алга куелган программаларны тормышка ашырдык, өметле проектлар өстендә эшләүне дәвам иттек. Безнең зур уңышыбыз: Кембридж системасы буенча инглиз теле укыту һәм балалар театрын үстерүдә беренче адымнар ясалды. Әлеге проектларның беренче уңышлары да бар.

Элеккечә, югары әхлаклылык, нык һәм дус гаиләләребез, елдан-ел арта баручы балаларыбыз безнең төп байлыгыбыз булып кала.

Яңа елда алдыбызда зур һәм әһәмиятле эшләр тора.
Бу, беренче чиратта, Бөек Җиңүнең 75 еллык юбилее. Киләчәк буыннарга дәһшәтле сугыш еллары турында дөреслекне җиткерү – безнең мөһим бурычыбыз.

Без түземсезлек белән музейның эшләп китүен көтәбез.
Яңа уку елыннан фольклор ансамбленең эшен ачып җибәрү проекты тора.

Без тотрыклылык һәм югары уку сыйфатын тәэмин итү өчен, барысын да эшләячәкбез. Тырыш хезмәт һәм бердәм булуыбыз моңа нык ышаныч бирә.

Кадерле дуслар! Яңа ел сезгә тынычлык һәм иминлек алып килсен, өйләрегез бәхет һәм балаларның шатлыклы көлүләре белән тулы булсын. Сезгә ихлас күңелдән саулык-сәламәтлек һәм муллык телим! Яңа 2020 нче ел белән!

**Г.С.Хәлиуллина, гимназия директоры**

# Magic World of Origami in English lessons.

Magic World of Origami in English lessons.



Origami in Japanese - bending the paper. **"ori"** it means - Japanese for "folded" and **"kami"** – it means "paper" and "God" at the same time. **Origami** - the art of paper sculpture, born in Japan. Famous Japanese origami master Akira Yoshizawa invented the "ABCs of origami." Origami has become popular not only in Japan but also in many countries of the world. Origami involves the creation of paper forms usually entirely by folding. Animals, birds, fish, geometric shapes, puppets, toys and masks are among the models that even very young children can learn to make in just one sitting.



Paper is the best thing you can use in your English lessons.

For example, these colorful boxes can be used to explain the new adjectives: funny, angry, kind, mad…. You can also change boxes inside. More than that boxes are the best things when you explain colors.

We achieve the result by creating different works. Occupation Origami develops creativity, intelligence, teaching work. The art of origami helps to create different products and to apply this knowledge in their studies.



Be creative!

# Тылсымлы Яңа ел!

Яңа ел – һәркемнең иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәренең берсе. Әмма бу бәйрәм турында без күп беләбезме соң? Яңа ел турында иң кызыклы фактларны җыярга булдык.

Яңа елны бәйрәм итү вакыты төрлечә булган. Аны язын да, җәй көне дә, көзен дә, без гадәтләнгәнчә, кыш көне дә бәйрәм иткәннәр. Хәзерге вакытта исә күпчелек илләрдә Яңа елны 31 нче декабрьдән 1нче гыйнварга каршы төндә бәйрәм итәләр.


Индонезиягә Яңа ел октябрьдә килә. Бар халык, Яңа ел костюмнарыннан киенеп, ел буе китергән үпкәләре өчен, бер-берсеннән ярлыкау сорап йөриләр. Кытайда Яңа ел бәйрәме ракеталар һәм шартлаткычлар авазыннан гөрләп тора. Элегрәк биредә шартлаткычлар ролен бамбук кәүсәләре үтәгән.

Монголиядә Яңа ел терлекчелек бәйрәме белән тәңгәл килә. Яңа ел төнендә төрле ярышлар үткәрелә. Европадагы кебек, монголлар да Яңа елны чыршы янында каршылыйлар. Күчтәнәчләрен күтәреп, Кыш бабай килә. Тик без купшы туннан күреп гадәтләнгән Кыш бабай биредә терлекче киемендә йортларның ишеген кага, ди.

1нче  гыйнварда японнар кояшны каршыларга урамга чыгалар һәм бер-берсенә бүләкләр бирешәләр.

Әгәр Яңа елда Италиядә булырга туры килсә, йортлар яныннан урабрак узыгыз. Биредә яшәүче халыкның ышануларына караганда, 31нче  декабрь төнендә никадәр күбрәк иске-москы әйбер ыргытсаң, Яңа ел шулкадәр күбрәк байлык китерәчәк икән.

Яңа ел бәйрәме турында уйлана башласак, һич тә борчылырга кирәкми. Яңа ел табынына ни телисең, шуны әзерләргә мөмкин, чөнки күселәр барысын да ярата. Яңа ел котлы булсын!


gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
Театр Кукол Экият
gimnaziya_official
Ответственность перед обществом и государством

# Туган көннәр



**Укытучылар:**
**Миләүшә Әхтәм кызы (07.12)**
**Тәнзилә Исрафил кызы (07.12)**
**Лилия Альберт кызы (17.12)**

**1 нче А сыйныфы:**
**Гайфетдинов Рамазан (09.12)**
**Мәхмүтова Индира (28.12)**
**Нуриев Алнур (06.12)**

**1 нче Б сыйныфы:**
**Билалова Эвелина (13.12)**
**Гәрәев Рамазан(03.12)**
**Гаязов Илмир (21.12)**
**Вәлиуллин Ринат (23.12)**

**2 нче сыйныф:**
**Билалова Айзилә (14.12)**
**Гомәров Илнур (08.12)**
**Исламова Дәлия (19.12)**
**Липин Ринат (04.12)**
**Мөхәммәтшин Әмир (02.12)**

**4 нче сыйныф:**
**Галиев Аяз (15.12)**
**Галиева Сылу (03.12)**
**Даутов Камил (05.12)**

**5 нче сыйныф:**
**Бәдертдинова Чулпан (06.12)**
**Сәхәбетдинова Айгөл (25.12)**
**Хөҗәтов Рияз ( 06.12)**

**6 нчы сыйныф:**
**Низамов Айдар (10.12)**

**7 нче сыйныф:**
**Газизова Язилә (25.12)**
**Закирова Эльвина (22.12)**
**Исламов Илдан (18.12)**
**Хаҗиев Булат (04.12)**

**8 нче сыйныф:**
**Маликова Камилә (17.12)**

**9 нчы сыйныф:**
**Зәйнуллин Рамазан (09.12)**

**10 нчы сыйныф :**
**Галимҗанова Лилия (27.12)**









**Баш мөхәррир** —Крашева Рузалина
**Әдәби консультант**-Гарипова Рузиля, Мусина Язилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Маликова Камилә, Авзалтдинова Камилә, Мулләхмәтова Айзилә
**Фотокорреспондент**-Яковлева Алсу
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745